СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 5-32 от «03» июля 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2024 елның 29 февралендәге «2024 елга Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында» 1-28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елга Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесенә 2024 елга Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 26 мартындагы «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планы турында» 10-6 карарын үз көчен югалтты дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Советының сәнәгать, транспорт, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы урынбасары Р.Р.Сәмигуллин

0000б9

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Советының
03.07. 2024 ел , № 5-32 карарына
1 нче кушымта

2024 елга «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

1 бүлек. Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган муниципаль милекне хосусыйлаштыру өлкәсендә сәясәтне тормышка ашыруның төп юнәлешләре һәм бурычлары

2024 елга Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) (алга таба – фараз планы) Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Көндәшлекне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру мәсьәләләрен җайга салучы башка норматив-хокукый актлар, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 31 октябрендә 10-35 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру турында Нигезләмә нигезендә эшләнгән.

Мамадыш муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның төп бурычы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары функцияләрен (вәкаләтләрен) һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнмәгән муниципаль милекне хосусыйлаштыру хисабына муниципаль милек структурасын оптимальләштерү.

Муниципаль милекне хосусыйлаштыру программасы түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдереләчәк:

- тулаем алганда, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы икътисады һәм аерым хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетына муниципаль милекне хосусыйлаштырудан планлаштырылган барлык керемнәрнең дә үз вакытында һәм тулаем керүе;

- муниципаль милекне хосусыйлаштырудан кергән акчалар хисабына җирле бюджетны тулыландыру;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы икътисадын һәм аның инфраструктурасын үстерү өчен инвестиция чараларын җәлеп итү;

2024 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) гамәлдә булу срогы дәвамында аңа Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә ала.

Ел дәвамында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкендә булган хосусыйлаштырылмаган муниципаль милек объектлары киләсе елга фараз планына кертелә.

## 2 бүлек. 2024 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль милек объекты исемлеге һәм характеристикасы

1.Муниципаль милек:

| № т/б | Исеме | Урнашу адресы | Хосусыйлаштыру ысулы | Фаразланган вакыты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | ПАЗ 423470 XIM4234KV80001113 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 1 квартал 2024 | |
| 2 | ПАЗ 32053-70 X1M3205EX70007603 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 1 квартал 2024 | |
| 3 | ПАЗ 3423470 X1M4234KVB0001107 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 1 квартал 2024 | |
| 4 | Фиат-дукато Z7G244000AS011891 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 2 квартал 2024 | |
| 5 | УАЗ 396269 | ТР, Мамадыш | ачык | 2 квартал | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | XTT39625940408187 | районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | аукцион | 2024 | |
| 6 | Фиат-дукато Z7G244000AS011892 | ТР, Мамадыш районы, Югары Берсут, авылы, 1нче Май урамы, 56 А | ачык аукцион | 2 квартал 2024 | |
| 7 | CHEVROLET NIVA 212300-55 X9L212300G0579304 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | | 2 квартал 2024 | |
| 8 | «Fiat Albea» XU3178000CZ146522, | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | | 2 квартал 2024 | |
| 9 | 16:26:340128:499 кадастр номерлы торак булмаган бина | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., Совет ур., 11/6 , №21 бина. | ачык аукцион | 2 квартал 2024 | |
| 10 | BMW маркалы автомобиль идентификацион номеры: (VIN) WBAKC81060CY67556 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 2 квартал 2024 | |
| 11 | Chevrolet Niva, 212300-55L X9L212300F0544263 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 3 квартал 2024 | |
| 12 | ГАЗ-3110 " XTH31100041202610 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 3 квартал 2024 | |
| 13 | CHEVROLET NIVA X9L212300H0612009 | ТР, Мамадыш районы, | ачык аукцион | 3 квартал 2024 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | | | |
| 14 | УАЗ-315196 XTT315196B0502314 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 3 квартал 2024 | |
| 15 | CHEVROLET NIVA X9L212300J0644122 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 3 квартал 2024 | |
| 16 | CHEVROLET NIVA X9L212300J0660625 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 3 квартал 2024 | |
| 17 | CHEVROLET NIVA X9L212300F0564934 | ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 3 квартал 2024 | |
| 18 | Камаз-Маркопола 3297 BRAVIS-0000011 X1F3297KMD0000031 | ТР,Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 3 квартал 2024 | |
| 19 | Шевроле Нива 212300-55 X9L212300J0660613 | ТР,Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 4 квартал 2024 | |
| 20 | Шевроле Нива 212300-55 X9L212300J0644125 | ТР,Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 4 квартал 2024 | |
| 21 | «Chevrolet Niva 212300-55LC» X9L212300E0529341 | ТР,Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, | ачык аукцион | 4 квартал 2024 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 23/33 й. | | | |
| 22 | «Fiat Albea» XU3178000BZ144559 | ТР,Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 4 квартал 2024 | |
| 23 | «Fiat Albea» XU3178000BZ144559 | ТР,Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 4 квартал 2024 | |

2. Муниципаль унитар предприятиеләрне җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләргә үзгәртеп кору юлы белән хосусыйлаштыру

| № п/п | Эшчәнлек төре,Муниципаль унитар предприятиенең исеме һәм урнашу урыны | Хосусыйлаштыру ысулы |
|---|---|---|
| 1. | Хезмәт күрсәтү, җәмәгать ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча эшчәнлек<br>Мамадыш муниципаль районы «шәһәр хуҗалыгы» МУП<br>ИНН 1626013093<br>ОГРН 1121675000105<br>422190, ТР, Мамадыш районы, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә үзгәртү |

».

**3 бүлек. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү**

Хосусыйлаштыру программасын тормышка ашыру, шул исәптән хосусыйлаштыру ысулларын һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыруның башлангыч бәясен үз эченә алып, аукцион үткәрү юлы белән sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгында урнаштырылачак.

Әлеге программада каралган хосусыйлаштыру шартлары турында Карар кабул итү муниципаль милекне хосусыйлаштыру максатларын һәм бурычларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.